| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 07.02.2025 274 **КАРАР**

2025 елның беренче яртыеллыгына торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

«2020-2025 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2025 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе нормативы турында» 2022 елның 22 декабрендәге 1111/пр боерыгы нигезендә, «Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр союзы» коммерциясез партнерлыгының «Социаль программалар максатларында торакның уртача базар хакы турында» 2025 елның 28 гыйнварындагы 32 номерлы хатына таянып, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның беренче яртыеллыгына яшь гаиләләргә торак сатып алуга яисә индивидуаль торак йорт төзүгә социаль түләү күләмен исәпләп чыгару өчен Алабуга муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры нормативын 132 500 сум күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары А.А.Томилинга йөкләргә.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026